РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 14 » 08 2023 г. №1202

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2007 елның 17 июлендәге 4 номерлы карары белән расланган «Ютазы муниципаль районы җитәкче составына, гражданнар оборонасы белән идарә итүче органнарга һәм халыкка хәбәр итүне оештыру тәртибе турында» Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Халыкка хәбәр итү системаларын булдыруга, реконструкцияләүгә һәм аларны даими әзерлек хәлендә тоту тәртибе турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 17 маендагы 769 номерлы карары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты

карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 17.07.2007 № 4 карары белән расланган «Ютазы муниципаль районы җитәкче составына, гражданнар оборонасы белән идарә итүче органнарга һәм халыкка хәбәр итүне оештыру тәртибе турында» Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 11 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Террорчылык куркынычы янаган очракларда, халыкка хәбәр итүнең һәм мәгълүмат бирүнең төп ысулы - «Халыкка хәбәр итү системаларын төзү, реконструкцияләү һәм даими әзерлек хәлендә тоту тәртибе турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 17 маендагы 769 номерлы Карары таләпләренә туры китереп, нинди ведомствога каравына һәм милек формасына

карамастан, үткәргеч тапшыру челтәрләре, радиотапшырулар һәм телевидение кулланып сөйләм мәгълүматларын тапшыру тора”.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы составында http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга .

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктураны үстерү буенча урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина